ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 163-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Э.Ю. Габдуллаҗанов, Д.В. Анисимов, Р.Р. Гайзатуллин, А.Ю. Егоров, О.Ю. Николаев тарафыннан кертелгән «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 163-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 17 марты
№ 592-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
Э.Ю. Габдуллаҗанов,
Д.В. Анисимов,
Р.Р. Гайзатуллин,
А.Ю. Егоров,
О.Ю. Николаев
тарафыннан кертелә

**«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы $2^2$ өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, № 10; 2014, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«$2^2$. Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашкан һәм (яисә) Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүгә каршы тору буенча, Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарына чиктәш Россия Федерациясе субъектларының чик буе территорияләрендә хәрби провокация барышында бурычларны үтәгән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның торак урыннары белән тәэмин ителү хокукы әлеге Законның 2 статьясы нигезендә исемлеккә кертелгән башка затларныкыннан өстен була.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларыннан эшләнде.

«Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» Федераль законның 8 һәм 8.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 15 декабрендәге 484-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законга торак урыннары белән тәэмин ителү хокукы өстен булган затларның исемлеген, аңа Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүгә каршы тору буенча, Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарына чиктәш Россия Федерациясе субъектларының чик буе территорияләрендә хәрби провокация барышында бурычларны үтәгән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны кертү юлы белән киңәйтү өлешендә үзгәрешләр кертелде.

Закон проектында «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы $2^2$ өлешенә (алга таба – 8-ТРЗ номерлы Закон) төгәлләштерә торган үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

Закон проектын кабул итү 8-ТРЗ номерлы закон нигезләмәләрен актуальләштерәчәк, шулай ук Россия Федерациясе территориясенә кораллы басып керүгә каршы тору буенча, дәүләт чигендә һәм махсус хәрби операция үткәрү районнарына чиктәш ил субъектларының чик буе территорияләрендә хәрби провокация барышында бурычларны үтәгән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәчәк.

Тәкъдим ителә торган үзгәрешләр рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.